**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Әтнә районының Кызыл Утар авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасы Әтнә районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Әтнә районының Кызыл Утар авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасы Әтнә районының Олы Мәңгәр авылындагы Ленин урамы территориясендә.

2. Түбәндәгеләр үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Әтнә районының Кызыл Утар авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1016 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Әтнә районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 8 ноябрендәге ПУ-1022 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 13 гыйнвар
№ ПУ-8